Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Күки авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 10**

Күки авылы 2017 елның 22 августы

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советының 2016 елның 1 апрелендә кабул ителгән 7 номерлы «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Күки авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында» карары һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советының 2016 елның 19 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында»гы 20 номерлы карарының 2 пункты үз көчен югалткан дип тану хакында

«Коррупциягә каршы тору өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 3 апрелендәге 64-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә, "Коррупциягә каршы көрәш турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12.1 маддәсе нигезендә муниципаль норматив хокукый актларны законнарга туры китерү максатларында “Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын яисә җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү тәртибе хакында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә

оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1.Үз көчен югалткан дип санарга:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советының 2016 елның 1 апрелендә кабул ителгән 7 номерлы «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Күки авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында» карары;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күкиавыл җирлеге Советының 2016 елның 19 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында»гы 20 номерлы карарының 2 пункты.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күкиавыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Күки авылы ,Яңа урамы, 5 нче йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Күки авыл җирлеге башлыгы

А.М.Бәдретдинов